**АННОТАЦИЯ**

Дәүләт стандартларына туры китерелеп 8 нче сыйныфта татар әдәбияты дәресләренә эш программасы түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1.”Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы(2004нче ел, 1нче июль)
2. "2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (2004нче ел, 11нче октябрь).
3. Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007нче ел, 1нче декабрь).
4. Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.
4.Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары(5-11нче сыйныфлар)-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.

**Дәреслек**: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия-А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Ә.Ганиева-4нче басма.-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2006.

| | | |
|---|---|---|
| **Каралды**<br>**Методик берләшмә җитәкчесе**<br>**_______ Рамазанова Р.Н.**<br>**Беркетмә № 1**<br>**25 нче 2017 нче ел** | **Килешенде**<br>**Уку-укыту эшләре буенча**<br>**директор урынбасары**<br>**_______ Г.Т.Исмәгыйлева**<br>**28 нче август 2017 нче ел** | **Раслыйм**<br>**Мәктәп директоры**<br>**_______ Г.Т.Сабирҗанова**<br>**Приказ № 71 август**<br>**28 нче август 2017 нче ел** |

**Татарстан Республикасы муниципаль**
**гомуми белем бирү бюджет учреждениесе**
**Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Сабирова Чулпан Рамил кызының**
**8 нче сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан**

# ***ИНДИВИДУАЛЬ***
# ***ЭШ ПРОГРАММАСЫ***

**Педсовет утырышында каралды**
**Беркетмә №1**
**28 нче август 2017 нче ел**

**2017-2018 нче уку елы**

## Аңлатма язуы

Программа Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законына нигезләнеп ( 2007 нче ел, 1 нче декабрь ), "Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа"га ( 5-11 нче сыйныфлар), МБББУ "Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең индивидуаль укыту турында нигезләмәсенә ( приказ №111 24.05.2011), ТР Министрлар кабинетының 2008 нче елның 16 июнендә чыккан "Инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү йөзеннән якын килеп, индивидуаль белем бирүнең 401 нче " нигезләмәсенә, инвалидларны яклау турында Россия Федерациясенең 1995 нче елның 24 нче ноябрендә чыгып, 2008 нче елның 14 нче июлендә үзгәртелгән 181 нче номерлы Федераль Законына нигезләнеп төзелде.

ТР Сарман муниципаль районы "Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбенең" озак дәваланырга мохтаҗ һәм инвалид балаларга гомумбелем бирү программасын үзләштерүне тәэмин итү һәм белем бирү хезмәтләрен күрсәтү өчен 2017-2018 нче уку елы планы.

Программа нигезенә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары алынды. Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп төзелде:

1."Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" Татарстан Республикасы Законы(2004нче ел, 1нче июль)

2. "2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы" (2004нче ел, 11нче октябрь).

3. Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007нче ел, 1нче декабрь).

4. Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.

5.Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары(5-11нче сыйныфлар)-Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2010.

Эш программасы стандарттагы минимумга нигезләнеп төзелде.

**Әдәбият укытуның максаты:**

Төрле жанрда эшләүче язучыларның иҗаты, халык җәүһәрләренең матур үрнәкләре мисалында матурлыкка соклана белү, иреклелек, туган илеңне ярату, кешелекнең уңай сыйфатларын тәрбияләү. Укучыларны мөстәкыйль фикер йөртә белергә, үз фикереңне курыкмыйча дәлилли белергә өйрәтү.

**Бурычлары:**

1) әдәби әсәрне сәнгатьле уку, аерым өзек, шигырьләрне ятлау;
2) бәя бирү ысулларын уңышлы куллана белү;
3) әсәр эчтәлеген таба белү, вакыйгаларны барлау;
4) төрле жанр әсәрләрен таный, өлешчә анализ ясый белү;
5) үз фикереңне дәлилли белү (телдән һәм язма);

Укыту планында 8 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан 9 атна исәбеннән (атнага 0.25 сәгать ) дәрес каралган.
Татар әдәбиятыннан тематик план"Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары"на (Фәрит Хатипов, 5-8 сыйныф, 2005) үзгәртүләр кертеп төзелде.

**Искәрмә**. „Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе"муниципаль белем бирү учреждениесенең „Укыту курслары һәм предметларыннан эш программалары төзелеше, аларны эшләү тәртибе турында" гы 29 нчы август 2016 нчы елда педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәнең 5 нче пунктына таянып , дәресләр бөйрәм көнннәренә туры килү сәбәпле, 8 нче А сыйныфында дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

**Мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары**

| УМК | Укытучы өчен методик әдәбият | Укучылар өчен әдәбият |
|---|---|---|
| **Дәреслек**: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия- А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Ә.Ганиева-4нче басма.-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2006.<br>**Программа**: “Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары” -Азат Әхмәдуллин, Фоат Галимуллин, Флера Ганиева, Фәнис Исламов-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010. | 1.Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Т.Ш. Гыйләҗев. Татар әдәбияты. Теория. Тарих. К.: “Мәгариф” нәш-ты, 2004<br>2. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. К.: ТКН, 2000.<br>3. Заһидуллина Д.Ф., Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. К.: “Мәгариф” нәш-ты, 2000<br>4.Гыймадиева Н.С., Ш.Г.Билалова Әдәбият дәреслекләре буйлап. К.: “Яңалиф нәшрияты,2006.<br>5. Әдһәмова Г., Татар әдәбиятыннан хрестоматия К.: “Яңалиф нәшрияты,2003. | 1. Әдәбият белеме сүзлеге.<br><br>2. Гыймадиева Н.С., Ш.Г.Билалова Әдәбият дәреслекләре буйлап. К.: “Яңалиф нәшрияты,2006.<br>3. Әдһәмова Г., Татар әдәбиятыннан хрестоматия К.: “Яңалиф нәшрияты, |

**Контроль төре:** сорауларга җавап, сәнгатьле сөйләм, сочинение, тест.

*Укыту-тематик планы*

| № п/п | **Бүлекләр** | Ничә дәрес |
|---|---|---|
| 1 | Дастан турында төшенчә. “Идегәй” дастаны. | 1 |
| 2 | Ф.Кәриминең тормышы һәм иҗаты. “Салих бабайның өйләнүе” хикәясе. | 1 |
| 3 | М.Фәйзи. Драматург турында белешмә. “Галиябану”драмасы | 1 |
| 4 | Ш.Камалның тормышы һәм иҗаты турында кыскача | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | белешмә. “Акчарлаклар” повесте. | |
| 5 | Һ.Такташ иҗаты турында тулырак мәгълүмат бирү. “Алсу”поэмасы. “Киләчәккә хатлар” поэмасы. “Мәхәббәт тәүбәсе | 1 |
| 6 | Н.Фәттах “Ител суы ака торур” романы. Тарихи роман турында төшенчә. | 1 |

**Эш программасының эчтәлеге**

1. Дастан турында төшенчә. “Идегәй” дастаны. Дастан героеның тарихи җирлеге. “Идегәй” дастаны. Ватан һәм милли азатлык мәсьәләләренең чишелеше, сәнгатьчә эшләнеше, тел байлыгы. “Идегәй” дастанынннан өзекне яттан сөйләү.-1с.
2. Ф.Кәриминең тормышы һәм иҗаты. “Салих бабайның өйләнүе” хикәясе. Әсәрнең эчтәлеге белән таныша башлау. Ф.Кәрими “Салих бабайның өйләнүе”. Хикәядә шул чордагы гореф-гадәтләрнең, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең төгәл чагылдырылуы. Салих карт холкындагы уңай сыйфатлар, кайбер ярамаган шөгыльләре. *Бәйләнешле сөйләм үстерү*. Хикәя буенча катлаулы план төзү.-1с.
3. М.Фәйзи. Драматург турында белешмә. “Галиябану”. Олы, саф мәхәббәтнең иҗтимагый тигезсезлек белән бәрелешүе *Бәйләнешле сөйләм үстерү*. Сочинение. “Галиябану һәм Хәлил – иске гадәт-йола корбаннары”.-1с.
4. Ш.Камалның тормышы һәм иҗаты турында кыскача белешмә. “Акчарлаклар” повесте.. Сезонлы эшчеләр тормышының яктыртылышы. Аларның өметләре акланмавы, канатсыз акчарлаклар хәлендә калулары Ш.Камал “Акчарлаклар” повесте. Гариф, Газизә, Шәрәфи карт образлары. Үзара мөнәсәбәтләрдәге җылылык, эчкерсезлек, самимилек. *Бәйләнешле сөйләм үстерү.* Конроль сочинение. “Егет кешене кыюлык бизи” яки “Гариф образы”.-1с.
5. Һ.Такташ иҗаты турында тулырак мәгълүмат бирү. “Алсу”поэмасы. Әсәрдә яшәү шатлыгы, оптимизм, үзеңне бәхетле тою хисләренең чагылышы. “Киләчәккә хатлар” поэмасы. 30 нчы еллар башындагы иҗтимагый тормышның, социаль-психологик каршылыкларның киң күренешен сурәтләү, киләчәккә ышаныч белдерү. “Мәхәббәт тәүбәсе”. *Бәйләнешле сөйләм үстерү*. ”Алсу” һәм “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмаларыннан өзекләрне яттан сөйләү.-1с
6. Н.Фәттах “Ител суы ака торур” романы. Н.Фәттах “Ител суы ака торур” романы. Болгар дәүләте тормышын, кабиләләр тартышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, сәүдә, мәдәният, дин мөнәсәбәтләрен, геройларның хисләрен тасвирлау. Сюжетка киеренкелек, җанлылык бирүдә Тотыш холкының роле. Тарихи роман турында төшенчә. Сочинение язуга әзерлек. “Үз халкыңны үз итсәң, ят халыкка кол булмассың”. *Бәйләнешле сөйләм үстерү.* Контроль сочинение. “Тарихлардан килгән хакыйкать”.-1с

.

7. Аяз Гыйләҗев. Биографик белешмә. “Язгы кәрваннар”. Авылда сугыш чоры яшьләренә килгән тормыш һәм хезмәт авырлыкларының чагылышы. Күңел төшенкелегенә бирелмәү, яшьлек хисләренең юл яруы. *Класстан тыш уку.* Аяз Гыйләҗев “Яра” повесте.-1с
8. С.Сөләйманова “Туган җирем, эчкән суым...”, “Кеше барыбер кошлар нәселеннән...”, “Кеше”, “Этюд”, “Сулар ага, күлләр күккә бага...”, “Тагын узды кыңгыраулы язлар” шигырьләре. Аларда хисләр байлыгы, күңел тирбәнешләренең табигыйлеге, поэтик бизәкләргә муллык. Сүз белән сурәт ясау осталыгы.-1с

**Календарь-тематик план**

| № | Дәреснең темасы, эчтәлеге | Эшчәнлек төре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1 | Дастан турында төшенчә. “Идегәй” дастаны. Дастан героеның тарихи җирлеге. | 1.Актуальләштерү. Халык авыз иҗаты. Төрләре.<br>2.Укытучы сөйләме. | 28.09 | 28.09 |
| 2 | Ф.Кәриминең тормышы һәм иҗаты. “Салих бабайның өйләнүе” хикәясе. Әсәрнең эчтәлеге белән таныша башлау. | 1. Мәгърифәтчелек әдәбияты һәм мәгърифәтче язучылар турында мәгълүмат бирү . | 19.10 | |
| 3 | М.Фәйзи. Драматург турында белешмә. “Галиябану”. Олы, саф мәхәббәтнең иҗтимагый тигезсезлек белән бәрелешүе. | 1. Әдәбият теориясе.<br>Музыкаль драма. Аның тууы турында мәгълүмат.<br>1. Рольләргә бүлеп уку. Театр атналыгына спектакль әзерләү.<br>2. Өлешчә анализ. | 23.11 | |
| 4 | Ш.Камалның тормышы һәм иҗаты турында кыскача белешмә. “Акчарлаклар” повесте. | Ш.Камалның тормышы һәм иҗаты турында кыскача белешмә бирү. “Акчарлаклар” повестен укый башлау. | 21.12 | |
| 5 | Һ.Такташ иҗаты турында тулырак мәгълүмат бирү. “Алсу”поэмасы. Әсәрдә яшәү шатлыгы, оптимизм, үзеңне бәхетле тою хисләренең чагылышы. “Мәхәббәт тәүбәсе”. | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү | 01.02 | |
| 6 | Н.Фәттах “Ител суы ака торур” романы. | 1. Укытучы лекциясе.<br>2. Әсәр белән таныша башлау. | 01.03 | |
| 7 | Аяз Гыйләҗев. Биографик белешмә. “Язгы кәрваннар”. Авылда сугыш чоры яшьләренә килгән тормыш һәм хезмәт авырлыкларының чагылышы. Күңел төшенкелегенә бирелмәү, яшьлек хисләренең юл яруы. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>Фикерләү сәләтен үстерү. | 05.04 | |
| 8 | С.Сөләйманова “Туган җирем, эчкән суым...”, “Кеше барыбер кошлар нәселеннән...”, “Кеше”, “Этюд”, “Сулар ага, күлләр күккә бага...”, “Тагын узды кыңгыраулы язлар” шигырьләре. Аларда хисләр байлыгы, күңел тирбәнешләренең табигыйлеге, поэтик бизәкләргә муллык. Сүз белән сурәт ясау осталыгы. | | 03.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | М.Юныс. Язучы турында кыскача белешмә. “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” повесте. Әсәрнең, тормыш материалыннан чыгып, икегә бүленүе. Бу өлешләрдә хикәяләү үзенчәлекләре. Образлар системасы. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Иҗади фикерләү сәләтен үстерү | 31.05 | |

**8 нче сыйныфны тәмамлаган татар балалары үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр**

- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;
- геройларга характеристика бирү;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
-дастан һәм аларның төрләрен аера белү;
-хикәя, фантастик хикәяне аера белү;
-шигырь һәм поеманың үзенчәлекләрен белү;
-уңай герой, лирик герой төшенчәләрен аера белү;
-әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү.